КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 декабрь г.Казань № 1268

Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә 2021 елның 11 маенда Казан шәһәрендәге «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә кылынган аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә, күмү урынына алып баруга бәйле чыгымнарны каплау буенча чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә 2021 елның 11 маенда Казан шәһәрендәге «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә кылынган аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә, күмү урынына алып баруга бәйле чыгымнарны каплау буенча чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 23 декабрь, 1268 нче
карары белән расланды

Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә
2021 елның 11 маенда Казан шәһәрендәге «175 нче гимназия»
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә кылынган аеруча
авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә,
күмү урынына алып баруга бәйле чыгымнарны каплау буенча чыгым йөкләмәләрен
тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан
Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә 2021 елның 11 маенда Казан шәһәрендәге «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә кылынган аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә, күмү урынына алып баруга бәйле чыгымнарны каплау буенча чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт (алга таба – шул ук эзлеклелектә аеруча авыр җинаять, муниципаль берәмлек, башка бюджетара трансферт) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансферт 2021 елда бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасы белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны күмүне оештыру һәм үткәрү;

аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны күмү урынына алып бару.

4. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансферт бирү шартлары:

аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыруга һәм үткәрүгә, күмү урынына алып баруга бәйле чыгымнарны каплау өчен җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә субсидия бирү тәртибен һәм җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны җирләүне оештыру, күмү урынына алып бару буенча күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслар белән тәэмин итү

максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлек йөкләмәсен күздә тоткан башка бюджетара трансферт бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү һәм Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Бюджетара башка трансфертны алу өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты бу Тәртип расланган көннән биш эш көне үткәнгә кадәр Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка); аңа җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан башкарылган фактик чыгымнарны һәм «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 9 статьясы нигезендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан алынган акча суммасын исәпкә алып, күмү буенча хезмәтләр күрсәтүгә расланган тарифлар нигезендә башкарылган башка бюджетара трансферт күләменең исәп-хисабы теркәлә;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең тулы күләмдә финанслашу өчен башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең булуы турында гарантия хатын;

күмү буенча хезмәтләр күрсәтү тарифларын раслау турында муниципаль хокукый акт күчермәсен.

6. Министрлык:

заявканы кергән көнендә терки;

заявканы теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансферт бирү турында йә башка бюджетара трансферт бирүне баш тарту турында карар кабул итә, карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә бу турыда муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хәбәр итә.

Бюджетара башка трансферт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документлардагы мәгълүматларның бу Тәртипнең 5 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве.

7. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертның күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ci = P_1 + P_2 – P_3,$$

монда:

Ci – муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме;

$P_1$ – җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан күмүне оештыру һәм үткәрү буенча башкарылган чыгымнар;

$P_2$ – җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан аеруча авыр җинаять аркасында һәлак булганнарны күмү урынына алып бару буенча башкарылган чыгымнар;

$P_3$ – җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә алынган акча суммасы.

8. Башка бюджетара трансферт Министрлык белән муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты арасында Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше һәм алардан файдалану шартлары;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе, күләме һәм сроклары;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансферт алучының башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлекнең башка бюджетара трансферттан максатчан файдалану йөкләмәләре;

Министрлык белән дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан башка бюджетара трансфертыннан файдалану йөкләмәләренең муниципаль берәмлек тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

9. Башка бюджетара трансфертны күчерү Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финан органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына гамәлгә ашырыла.

10. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты 2022 елның 20 гыйнварына кадәр финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансферт торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турындагы хисаплылыкны Килешүдә каралган тәртип һәм форма нигезендә Министрлыкка тапшыра.

11. Бюджетара башка трансферттан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелегенең Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән күрсәткечен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

12. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара

трансферттан максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

13. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансферт 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keремeнә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемeнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемeнә түләтелергә тиеш.

14. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, башка бюджетара трансферт муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2022 елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

15. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары бу Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферт бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

16. Башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктлары нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

17. Башка бюджетара трансферттан максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.